# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ

**өченче чакырылыш егерме җиденче утырышы**

**карары**

**2018 елның 19 сентябре** **№ 87**

**“Татарстан Республикасы**
**Теләче муниципаль районы**
**Шәтке авыл жирлеге”**
**берәмлегендә кумәк**
**тыцлаулар (иҗтимагый**
**фикер алышу) оештыру**
**һәм уздыру тәртибе**
**турындагы Нигезләмәне**
**раслау хакында**

“Россия Федерациясендә жирле Үзидарә оештыруның гомуми принциплары» турындагы 6 нчы октяберендәге 2003 елныц 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге Советы карар кабул итте:

1. “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” берәмлегендә ачык тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы**
**Теләче муниципаль районы**
**Шәтке авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Г.Кадыйров**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге Советы Карарына кушымта

# “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ” МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ ХАЛЫК АЛДЫНДА ТЫҢЛАУЛАР (ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР АЛЫШУ) ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

“Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” берәмлегендә күмәк тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә ) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле узидарә оешмасынын гомуми принциплары турында”гы 2003 елнын 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә эшләнде.

## 1 Булек .
## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР
### 1 Статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә тубәндәге Төп төшенчәләр кулланыла:

**ачык тыңлаулар -** «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге халкының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларыньң проектларын бергәләп тикшерү аша җирле узидарә органнары тарафыннан карарлар кабул иту процессында, шулай ук, федераль законлылык, Әлеге Карар белән билгеләнгән сораулар өчен фикер алышуда катнашу хокукларын гамәлгә ашыру формасы;

**инициатив төркем -** ачык тыңлауларда катнашу хокукы булган Россия Федерациясе гражданины яки гражданнар төркеме; **җәмәгатьчелек вәкиле** - ачык тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча фикер алышуда, жәмәгать тыңлауларында катнашу хокукы булган физик зат, шул исәптән юридик затлар, берләшмәләр вәкилләре;

җәмәгатьчелек вәкилләренэ хезмәт вазыйфалары кушканча ачык тыңлауларга куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүче җирле узидарә органнары, яки дәүләт хакимияте вәкилләре, яки бушка булмаган килешү нигезендә аларнын эшчәнлегендә катнашучы затлар керми;

**ачык тыңлауларда катнашучылар -** җирле узидарә органнары һәм аларнын вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, ачык тыңлаулар экспертлары, ачык тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты әгъзалары ;

**ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булган катнашучылар -**

җирле Үзидарә органнары аларның вәкилләре, Әлеге Нигезләмәнең бнчы

маддәсендә билгеләнгән срокларда оештыру комитетына ачык тыңлаулар мәсьләләре буенча чыгыш ясауга Үзләренең гаризаларын биргән җәмәгатьчелек вәкилләре;

**оештыру комитеты** - ачык тьңлауларны әзерләү һәм Үткәрү буенча оештыру эшлэрен гамәлгә ашыручы, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район" муниципаль берәмлеге җирле Үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге дэүлэт Советы депутатларыннан, җәмәгатьчелек һәм гражданнарның инициативалы теркемнэре вәкилләреннән формалашкан (оешкан) коллегиаль орган;

**иҗтимагый фикер алышу -** җәмәгать күзәтчелеге (контроле) максатларында кулланылган иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр , шулай ук җирле Үзидарә органнары карарлары проектлары буенча халык алдында (публично) фикер алышу. Бу фикер алышуда тиешле карар мәнфәгатьләренэ кагылган җирле Үзидарә органнарының һәм оешмаларның вәкаләтле затларының, гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләренең катнашуы мэҗбүри.

**ачык тыңлаулар эксперты** - ачык тыңлаулар мәсьәләләре буенча махсус белемнәре булган һәм бу статуста вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән зат. Эксперт язмача рәвештә ачык тыңлаулар мәсьәләләре буенча рекомендацияләр тәкъдим итә һәм , аларны аргументацияләү өчен, фикер алышуларда катнаша.

"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышу»;

## 2нче статья. Ачык тыңлаулар уздыру максаты

Ачык тыңлаулар Әлеге максатларда үткәрелә:

"Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге » җирле муниципаль берәмлеге халкы катнашында мәҗбүри тәртиптә ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый актларның проектларын тикшерү .

ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча җәмәгать фикерен ачыклау һәм исәпкә алу.

ачык тыңлауларны әзерләү, уздыру һәм нәтиҗәләрен билгеләү экспертларның ачыклыгы, хәбәрдарлыгы, иреклелеге, бәйсезлеге принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3нче статья. Ачык тыңлауларга чыгарылган сораулар

1. Ачык тыңлаулар җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча үткәрелә. Ачык тыңлаулар нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен тәкъдим рәвешендә була.

2. Ачык тыңлауларга мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарны, конституцияне (устав) яки Россия Федерациясе субъекты законнарын төгәл итеп яңадан кабул итү формасында, Уставны шушы норматив хокукый актлар халәтенә китерү максатларында, Уставка үзгәрешләр кертелә. Шул очрактан кала, “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының проекты (алга таба - Устав), шулай ук Уставка Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Советы Карары проекты.

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап (отчет);

3) “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең соңиаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеген үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр.

Чыгарма(исключение):

2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмасының гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 13нче статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеген үзгәртеп кору өчен “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге халкының тавыш бирҮ юлы белән яки гражданнар жыеннарында ризалыгы таләп ителә;

5) генераль план проекты, җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелешләр проекты, территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне куздә тоткан проект, җир участогын яки капиталь төзелеш обьектын кулланунының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рохсәт бирү карары проекты, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карары проекты, капиталь төзелеш объектлары реконструкцияләре, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда җир участокларының һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән кулланылышының бер төрен шундый башка кулланылыш төренә үзгәртү сораулары буенча...,

6) халык алдында сервитутлар билгеләү сораулары;

7) җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты;

8) федераль законлылык тарафыннан билгеләнгән башка сораулар;

3. һәр мәсьәлә буенча төрле яклап һәм тулысынча фикер алышуга каршылык булмаган очракта, берничә мәсьәлә буенча бер ук вакытта ачык тыңлаулар үткәрергә рөхсәт ителә;

4. Башка финанслау Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнмәгән булса, ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру җирле бюджет хисабына финанслана.

**4нче статья. Ачык тыңлаулар инициаторлары**

Ачык тыңлаулар, Регламент нигезендә, “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Советы, (алга таба - Совет), “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба - Башлык) инициативасы, халык инициативасы буенча Үткәрелә.

Ачык тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы 10 кешедән дә ким булмаган, 18 яше тулган гражданнар төркеменнән булырга мөмкин .

## 2нче булек. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

**5нче статья. Ачык тыңлауларны билгеләү**

1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар, Совет карары белән билгеләнә .

Башлык инициативасы буенча уткәрелә торган ачык тыңлаулар, “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгы карары белән билгеләнә.

Ачык тыңлаулар Россия Федерациясе канунчылыгы тарафыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр буенча үткәрелә.

2. Ачык тыңлаулар уздыру турында халыкның инициативасын белдерү өчен һәм инициативаны күтәреп алу буенча халыктан имзалар җыю өчен 10 кешедән дә ким булмаган инициатива төркеме формалаша.

2.1. Инициатива төркеме Советка тәкъдим итә:

1 нче номерлы кушымта нигезендә, гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган форма буенча, ачык тыңлаулар мәсьәләсен күрсәтеп, ачык тыңлауларны билгеләү турындагы гариза һәм аларны уздыруның мөкимлеген дәлилләү;

- муниципаль акт проекты;

- (фикер алышу өчен җәмәгать тыңлауларына куелган очракта) муниципаль хокукый актнын максатларын һәм Төп Нигезләмәләрен, аны кабул итүнең мөкимлеген дәлилләгән анлатма язуы;

- (гамәлгә ашыру өчен өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп итә торган муниципаль хокукый актны, җәмәгать тыңлауларына карау өчен куелган очракта) финанс-икътисадый нигезләү;

-2 нче номерлы кушымта нигезендәге форма буенча, гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

- гражданнарның инициатив төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

- (муниципаль хокукый актны җәмәгать тыңлауларына карау өчен куелган очракта) битләр санын, шулай ук муниципаль хокукый акт проекты докладчысын күрсәтеп инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән, исемлекле иниңиатив төркем вәкаләтле вәкиленең вәкиле тарафыннан имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган (сопроводительное) хат;

Гариза һәм беркетмә рәислек итүче (гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиленең вәкиле ) һәм инициатив төркем

жыелышының сәркатибе тарафыннан имзаланган булырга тиеш;

2.2. Әгәр Советка бер үк вакытта чын статьяның 2.1 пунктчасында билгеләләнгән барлык документлар да тәкъдим ителгән булса, гариза бирелгән булып санала;

2.3. Советка гариза һәм аңа өстәлгән документлар кергән көннән алып 30 көнлек срок эчендә, җәмәгать тыңлаулары уздыруны хуплаган халыкның - чын Нигезләмә нең 3 нче номерлы кушытасы формасы буенча “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүче 18 яшь тулган халыкның гомуми саныннан 1% ким булмаган яшәүчеләрнең имзалары инициатив төркем тарафыннан җыелган һәм тапшырылган булырга тиеш.

Имзалар Советка җәмәгать тыңлаулары уздыру инициативасын тәкъдим иту турындагы гариза биргән көннән алып жыелырга мөмкин.

Кул кую кәгазенә кул куелмаган ысул яки карандаш белән мәгълуматлар кертергә рохсәт ителми. Гражданнар турындагы һәм даталарда тиешле мәгълүматләрдәге төзәтүләрне язылу кәгазенә кертү һәм раслау имзалары, шуңа бәйле рәвештә , гражданнар һәм имзаларны җыючылар тарафыннан килешенгән булырга тиеш.

2.4. Язылу кәгазьләре тапшырылганнан алып, 10 көн эчендә Совет эш төркеме төзи һәм язылу кәгазьләрендә тәкъдим ителгән мәгълүматларны тикшеру уздыра.

Кул кую кәгазьләрендәге имзаларны һәм мәгълуматларны тикшеру нәтиҗәләре буенча, имза хакыйкый яисә хакыйкый тугел дип таныла ала. Чын Нигезләмә нигезендә Әлеге имзалар хакыйкый тугел дип билгеләнмәгән очракта хакыйкый була.

Хакыйкый булмаган имзалар яки имзалар җыю тәртибен бозып җыелган һәм (яки) тутырылган язылу кәгазе дип:

1) Имзалар җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2) “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүче халыкның 18 яше тулмаган вәкилләре;

3) Кул кую кәгазенә үз кулы белән үз имзасын кую датасын күрсәтмәгән гражданнарның имзасы;

4) кул куелмаган ысул яки карандаш белән мәгълуматлар кертелгән имзалар;

5) Гражданнар турындагы һәм даталарда тиешле мәгълүматләрдәге төзәтүләрне язылу кәгазенә кертү һәм раслау имзалары (ул төзәтүләр гражданнар һәм имзаларны җыючылар тарафыннан махсус килешенмәгән очракта);

6) Формасы 3нче номерлы кушымтадагы чын Нигезләмә таләпләренә туры килми торган кул кую кәгазендәге барлык имзалар таныла.

Тикшеру нәтиҗәләре кул кую кәгазьләренең тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (4нче номерлы кушымта).

2.5. Чираттагы Совет утырышында, кул кую кәгазьләре кергән көннән 15 көнлек вакыт дәверендә , ачык тыңлаулар билгеләү турындагы карар яисә

ачык тыңлаулар турындагы гаризаны кире кагу карары кабул ителә , әгәр :

1) ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр җирле узидарә органнары компетенциясенә кермәсә (Әлеге Нигезләмәнен 3нче номерлы искәрмәсендәге очрактан кала);

2) ачык тыңлауларны уздыру турындагы халык инициативасын алга чыгару өчен тәкьдим ителгән хакыйкый имзалар саны гына җитми ;

3) алга чыгару инициативасының тәртибе үтәлмәгән;

4) каралырга тәкьдим ителгән муниципаль норматив хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, башка норматив хокукый актларга туры килми;

5) шушы мәсьәлә чыгарылган тыңлаулар уздырылган датадан соң елдан кимрәк вакыт узган.

2.6. Ачык тыңлаулар билгеләү турындагы гаризадан тайпылу, ачык тыңлауларны билгеләү өчен, баш тарту китереп чыгарган җитешсезлекләрне бетергән очракта, инициатив төркем тарафыннан документларны кабат кертүгә каршылык булып тормый.

2.7. Ачык тыңлауларны билгеләү мәсьәләсе Совет тарафыннан Совет регламенты нигезендә карала.

2.8. Ачык тыңлаулар билгеләү турындагы гаризадан тайпылу булган очракта, Совет, эшче көннәрдә хисапланган 5 көнлек срокта, гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле адресына язма мотивлаштырылган хәбәрнамә җибәрә (юллый).

3. Ачык тыңлауларны билгеләүче совет, Башлык, тыңлауларның мәсьәләсе , вакыты, һәм үткәрү урыны, оештыру комитеты составы, исәпкә алу буенча тәкьдимнәр тәртибе һәм ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында мәгълүматле тиешле муниципаль актлар кабул итәләр .

Ачык тыңлауларны үткәрү датасы, федераль канунчылык, Устав һәм әлеге Нигезләмә тарафыннан башка билгеләү булмаганда, ачык тыңлаулар билгеләү турындагы муниципаль хокукый акт кабул ителгән көннән 30 көнлек срокта билгеләнә .

### 6 нчы статья Ачык тыңлаулар турында мәгълумат биру.

1. “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге халкына ачык тыңлаулар турында игълан бирү, тыңлаулар уздырган көнгә кадәр эш көннәрдә хисапланган 10 көнлек дәвердә, (федераль канунчылык, Устав һәм әлеге Нигезләмә тарафыннан башка билгеләү булмаганда), ачык тыңлаулар билгеләү турындагы муниципаль хокукый акт турында фикер алышуның проект-кушымтасы белән муниципаль хокукый акт билгеләү турында игълан итү (аны карау өчен ачык тыңлауларга керткән очракта), массакүләм мәгълумат чараларында, рәсми сайтта һәм (яки) башка мәгълумат системалары өчен мәгълумат стендында бастырып чыгару юлы белән башкарыла.

1.1 Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре массакүләм мәгълумат чараларында,

“Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм (яисә) башка мәгълумат системалары һәм мәгълумат стендларында басылып чыга.

Мәгълүмати стендлар яхшы күренә торган урыннарда, мәгълүмат кулланучыларның күрә алу мөмкинлекләрен тәэмин итүне исәпкә алып урнаштырыла.

Мәгълумат стендларны урнаштыру, эргономика таләпләренә туры китереп, мәгълүмат кулланучынын озак вакытлар мэжбүр ителгән унайсыз халәттә тору кирәклеген гамәлдән чыгарып гамәлгә ашырылырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны төсле рәвештә бизәү эстетик таләпләргә туры килергә тиеш. Мәгълүмати стендлар, мәгълүмати битләр сыярлык А4 форматлы кесәләр белән тулыландырылырга мөмкин .

2. Җәмәгать тыңлауларында яки җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү мәйданы, шулай ук проект экспозициясенә килүчеләргә консультация бирү вакыты, килештерү буенча гавами тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында хәбәр итүгә кертелә.

Экспозиция эшләгән чорда килүчеләр өчен консультацияләр, проект турында басма мәгълүмати материаллар тарату оештырыла.

Экспозициягә килүчеләр тикшерелүче проектка, мәсьәләгә карата үзләренең тәкъдимнәрен, кисәтүләрен язмача рәвештә экспозициягә килүчеләрнең исәбен алу һәм тәкъдимнәр, искәрмәләр язу өчен тиешле китапка (журнал) кертергә хокуклы.

Экспозиция проектына:

- проект;
- проектка анлатмалы хат;
- Россия Федерациясенең законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә алынган документлар килештерүләре күчермәләре;
- ачык тыңлаулар яисә проект буенча иҗтимагый фикер алышуны (массакүләм мәгълүмат чарасынын ял мәгълүматларын күрсәтеп) уздыру турында мәгълүмати хәбәр итүне бастырып чыгару күчермәсе;
- тикшерелүче проект буенча гражданнарны хәбәрләү максатыннан, (проектнын әзерләү (эшләү) оештыручысы андый материаллар белән тәэмин иткән очракта) башка мәгълүмати һәм демонстрацион материаллар тапшырыла;

## 3 булек. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ҺЭМ УЗДЫРУ

### 7нче статья. Ачык тыңлауларны әзерләүне оештыру һәм уздыру

1. Ачык тыңлаулар “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегендә яшәүче халык өчен унайлы вакытта үткәрелә (ачык тыңлауларны эш көне булмаган вакытларда 11.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә яисә эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән башлап

22.00 сәгатьтән дә сонга калмыйча үткәрергә киңәш ителә).

2. Халык алдында тыңлауларны билгеләү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органынын оештыру комитетын “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең вэкиллекле органы депутатларыннан, “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты хезмәткәрләреннән, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән, гражданнар инициатив төркемнәреннән торган, (әгәр ачык тыңлауларның уздыру инициаторы булып гражданнарның инициатив төркеме чыгыш ясаса) саны 5 кешедән ким булмаган оештыру комитеты формалаштыра.

Оештыру комитеты, формалашканнан соң 3 көннән дә соңга калмыйча, беренче утырышта үз составыннан рәис, рәис урынбасары һәм сәркатип сайлый. Оештыру комитеты, утырышта әгъзаларының яртысыннан артыгы булганда, карарлар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру комитеты катнашырга теләүчеләрнең тыңлаулар үткәрелә торган бинага каршылыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

Оештыру комитеты тыңлаулар уздырыла торган көнне ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Җәмәгать тыңлауларында рәислек итүче булып оештыру комитеты рәисе тора. Рәислек итүче ачык тыңлауларны ача, тыңлаулар буенча сорау (сораулар), тыңлауларны үткәрү тәртибенә карата тәкъдимнәр яңгырата, үзе, сәркатибе һәм экспертлар белән таныштыра, тыңлаулар үткәрүнең инициаторларын атый. Оештыру комитеты сәркатибе ачык тыңлаулар беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче фикер алышү буенча үткәрелә торган мәсьәләне игълан итә һәм ачык тыңлаулар үткәрү инициаторлары белән вәкаләтле вэкиллек итүче затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясау хокукына ия булган ачык тыңлауларда катнашучыларга сүз бирә.

Чыгышлар чираты оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән гаризалар бирелу чираты белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар, узләренең рекомендацияләрен алып ташларга һәм (яки) ачык тыңлауларның башка катнашучылары тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәренә кушылырга хокуклы.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча җирле әһәмияткә ия, ачык тыңлауларга чыгарылган сорауны (сорауларны) читү буенча бердәм тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр исемлеге төзелә (чыгарма булып ачык тыңлауларда катнашучылар алып ташлаган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр тора).

6. Рәислек итүче, тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр белән йомгаклау документы төзегәннән соң, җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итунең (сораулар) йомгаклау вариантын катнашучылар тавыш бирүенә куя.

Ачык тыңлауларда мәсьәләне хәл иту ачык тавыш биру юлы белән теркәлгән тыңлауларында катнашучыларның гади купчелек тавышы белән кабул ителә.

Тыңлауларда катнашучы һәр кеше бер тавышка ия, аны ул җирле әһәмияттәге мәсьәләнең тәкъдим ителгән карары өчен (аңа каршы яки тавыш бирудән тыелып торам дип) бирә. Тавыш биру нәтиҗәләре беркетмәгә теркәлә (кертелә). Беркетмә ачык тыңлаулар рәислек итүчесе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана.

7. Ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә, ачык тыңлауларны уздырганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә төзелә (6нчы номерлы кушымта), анда:

1) ачык тыңлауларга чыгарылган сорау (сораулар);

2) ачык тыңлауларны үткәрүнең инициаторы (башлап йөрүчесе);

3) ачык тыңлауларны билгеләү турындагы хокукый актның атамасы, датасы, номеры, шулай ук аны бастырып чыгару (халыкка житкерү) датасы;

4) ачык тыңлауларны үткәрүнең датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;

5) ачык тыңлауларны үткәрүче оештыру комитеты;

6) ачык тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясарга хокук алучылар турында мәгълумат;

7) ачык тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге сорауны (сорауларны) чит итү буенча тәкъдимнәрнең һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге. Чыгарма: ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан алып ташланган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр;

8) җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;

9) ачык тыңлауларда катнашучыларның тавыш биру нәтиҗәләре күрсәтелә.

8. Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмә оештыру комитетының рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана һәм ачык тыңлауларны уздырганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә бастырылырга (халыкка житкерелергә) тиеш була.

9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә җирле узидарә органы, мәсьәләләрне һәм сорауларны кабул иту, ачык тыңлауларга чыгару буенча жаваплы кеше тарафыннан мәжбури каралырга тиеш.

10. Бәяләмә нәтиҗәләре, ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне җирле узидарә органы вәкаләтле вәкиле караганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә, мәжбури тәртиптә ачык тыңлаулар инициаторлары тарафыннан муниципаль берәмлек халкына бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән житкерелә.

11. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә, Россия Федерациясе законлылыгы тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш, тәкъдим рәвешендә була.

## 4нче булек. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК УСТАВЫНЫҢ ПРОЕКТЫ, УСТАВКА УЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДАГЫ СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ БУЕНЧА ОТЧЕТЫ, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕ УЗГӘРТЕП КОРУ МӘСЬӘЛӘСЕ , МУНИЦИПАЛЬ

## БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**8нче статья. “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге” муниципаль берзмлеге Уставының проектын һәм Уставка узгәрешләр кертү турындагы Совет карары проектын жәмәгать тыңлауларында карау үзенчәлекләре**

1. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы Устав проекты һәм Совет карарлары проекты, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештырунын гомуми принциплары турында”гы 2003 елнын 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законында һәм Уставта каралаган үзенчәлекләрне исәпкә алып, ачык тыңлауларда карала.

2. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы Устав проекты һәм Совет карарлары проекты Совет тарафыннан аны кабул итү турындагы мәсьәләне карауга 30 көннән дә кичекмичә рәсми бастырылырга (халыкка житкерелергә) тиеш. Бер үк вакытта күрсәтелгән проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, анын буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында Совет карары басылып чыга.

Уставка Россия Федерациясе Конституциясе Нигезләмәләренен, федераль законнарнын, Татарстан Республикасы Конституциясенен, Татарстан Республикасы законнарынын төгәл кабатлап эшләү кебек формадагы үзгәрешләре кертелгәндә, Уставны шушы норматив хокукый актлар халәтенә китеру максатларында, Совет карарларынын Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук анын буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе турындагы проект буенча тәкъдимнәр исәп тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

3. Устав проекты яки Совет карары проекты буенча Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы ачык тыңлаулар, курсәтелгән проектлар бастырып чыгарылганнан сон, кимендә 10 көн дигәндә, Устав тарафыннан билгеләнгән вакытта үткәрелә.

4. Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт Советы карары проекты яки Устав проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

**9нчы Статья. Ачык тыңлауларда җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше буенча отчет биру үзенчәлекләрен карау**

1. Җирле бюджет проекты һәм анын үтәлеше турындагы еллык отчёт ачык тыңлауларда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар, Устав, « Татарстан Республикасы» Теләче муниципаль районы мунициипаль берәмлегендә бюджет процессы турында”гы Нигезләмә тарафыннан каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

2. Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлауларны һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы отчётны гамәлгә ашыручы орган булып оештыру

комитеты тора.

Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турындагы карарны кабул итүче һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы отчётны гамәлгә ашыручы орган булып муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тора.

3. Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында, җирле бюджет үтәлеше турындагы отчёт буенча карарлар, кабул ителгәннән соң 10 көнлек срокта бастырылырга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты буенча ачык тыңлаулар, җирле бюджет үтәлеше турындагы отчёт (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап) җирле бюджет проекты бастырып чыгарылганнан соң, ким дигәндә, 15 календарь көннәреннән соң үткәрелә.

### 10нчы Статья. Җәмәгать тыңлауларында муниципаль берәмлекнең соңиаль-икътисади усешенең стратегиясе проектын карау үзенчәлекләре.

Муниципаль берәмлекнең соңиаль-икътисади усешенең стратегиясе проектларына кагылышлы мәсьәләләр, 2003 елның 6нчы октябендэге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принңиплары турында”гы Федераль закон, 2014 елның 28 нче июнендэге 172-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында”гы Федераль закон тарафыннан каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып ачык тыңлауларга чыгарыла.

### 11нче Статья. Муниципаль берәмлекне узгәртеп кору турындагы мәсьәләне жәмәгать тыңлауларында карау үзенчәлекләре.

1. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә буенча ачык тыңлаулар 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принңиплары турында”гы Федераль законның 13нче маддәсендә каралган очракларда үткәрелә. Чыгарма: курсәтелгән Федераль законның 13нче маддәсенең 5нче өлеше.

3. Мунициипаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы сораулар буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

### 12нче Статья. Иҗтимагый фикер алышуларда, ачык тыңлауларда мунициипаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча сораулар карау үзенчәлекләре.

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш проектларына, территорияләрне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау проектларына, территорияләрне төзекләндерү проектларына, алда курсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күз алдында тотучы проектларга, җир участогын яки капиталь төзелеш объектын кулланунын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, рөхсәт ителгән тезелешнең аерым параметрларыннан

кире кагылуга рөхсәт биру карары проектларына, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир участогын һәм капиталь төзелеш объектын куллануның рөхсәт ителгән бер төрен башка шундый ук куллану төренә кагылган мәсьәләләр, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы тарафыннан билгеләнгән Нигезләмәләрен исәпкә алып, шулай ук иҗтимагый фикер алышуга чыгарыла ала.

Җирлекләрнең генераль планнарының, шәһәр округларының генераль планнарының проектлары буенча җәмәгать фикер алышуын, ачык тыңлауларны оештыруның һәм уздыруның үзенчәлекләре Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексының 28нче маддәсендә китерелгән.

Җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына (алга таба - иҗтимагый фикер алшу яки ачык тыңлаулар) үзгәрешләр кертүне күздә тоткан җирлекләрнең генераль планнарының, шәһәр округларының генераль планнарының проектлары буенча җәмәгать фикер алышуы, ачык тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуда яки ачык тыңлауларда катнашучыларны, иҗтимагый фикер алышуда яки ачык тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин иту максатларында, иҗтимагый фикер алышу яки ачык тыңлаулар уздырганда торак пункт территориясе өлешләргә буленгән булырга мөмкин .

Иҗтимагый фикер алышуларның яки ачык тыңлауларның вакыты, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр итүдән алып иҗтимагый фикер алышуларның яки ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бастырып чыгаруга кадәр муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан кимрәк, өч айдан артыграк була алмый.

Җирле администрация Башлыгы, иҗтимагый фикер алышуларның яки ачык тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып:

1) генераль планның проекты белән ризалыгы һәм аны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына җибәрү турында;

2) генераль планның проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында карар кабул итә.

**13нче маддә. Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча ачык тыңлаулар уздыруның үзенчәлекләре**

1. Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча ачык тыңлауларда катнашу хокукына территориясендә җәмгыять сервитутлары билгеләү каралган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә даими яисә күбесенчә яшәүче, тыңлаулар үткәрү көненә 18 яше тулган һәр граждан ия.

Гражданнарның ачык тыңлауларында катнашуы үз теләкләре белән башкарыла. Ачык тыңлауларда «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә

урнашкан иҗтимагый берләшмәләр, барлык милек формаларының коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар катнашучылар була ала.

2. Ачык тыңлаулар 13 маддәнең 1 пунктында курсәтелгәнчә, вәкаләтле орган яки физик һәм юридик затларның инициативасы буенча үткәрелә. Ачык тыңлауларны үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

3. Ачык тыңлауларны уздыру турында карар кабул ителгәннэн соң 7 эш көне дәвамында вәкаләтле орган аларны үткәрү турында «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль актларының публикациясе өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълумат чараларында бастыра.

Ачык тыңлаулар ачылыр алдыннан аларның катнашучыларын:

юридик зат өчен - юридик затның тулы исемен, дәүләт теркәве мәгълүматләрен;

шәхси эшмәкәр өчен - исем-фамилиясен, атасының исемен, шәхси эшмәкәр сыйфатында гражданинның һәм дәүләт теркәве мәгълуматларын;

физик затлар өчен - исем-фамилиясен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын курсәтеп, мәжбури теркәу үткәрелә.

4. Ачык тыңлауларның нәтиҗәсе аларны уздыруның датасы һәм урыны, катнашучылар һәм анда булганнарның саны, ачык тыңлауларның рәисенең, сәркатибенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, чыгышларның эчтәлеге, тавыш биру нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм ачык тыңлауларның рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалаштырыла. Беркетмәгә ачык тыңлауларда катнашучыларның исемлеге беркетелә.

5. Жәмгыять сервитутларын билгеләү буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләре

вәкаләтле орган тарафыннан каралалар һәм җәмгыять сервитутларын билгеләү өчен мөмкин булган кирәкле документларга кушылалар.

Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе срогы - өч ел. Вәкаләтле орган житәкчесе жәмгыять сервитутларын билгеләү буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен саклау өчен жаваплы.

**14нче Статья Ачык тыңлауларда җылылык белән тәэмин иту схемаларының проектын карау үзенчәлекләре**

Җылылык белән тәэмин иту схемаларының проекты буенча ачык тыңлаулар 2012 елның 22 февралендәге “Җылылык белән тәэмин иту схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында”гы Россия Федерациясе Хекумэте карарының 154 нче номеры нигезендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 1 нче Кушымта

**ХАЛЫК АЛДЫНДА ТЫҢЛАУЛАР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

______ кеше санында инициатив төркем, исемлек теркәп бирелә, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге халыкның инициативасы буенча түбәндәге сораулар буенча ачык тыңлаулар билгеләргә тәкъдим итә:

Ачык тыңлаулар уздыруның мөкимлеген дәлилләү:

Кушымта (чынлыкта курсэтелгэн документлар фаразлана):

1) муниципаль хокукый акт проекты (кертелгән очракта);

2) аңлатма хаты;

3) финанс-икътисадый нигезләү (гамәлгә ашыру өстәмә матди чыгымнар һәм башка чыгымнар таләп иткән муниципаль хокукый акт кертелгән очракта);

4) гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

5) гражданнарның инициатив төркемен тезу турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

6) бергә теркәп җибәрелә торган хат.

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле ________________________________

(имза) (Ф. И. О.)

Гражданнарның инициатив төркеме сәркатибе ____________ ______________

(имза) (Ф. И. О.)

«Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы
Шәтке авыл жирлеге » муниципаль
берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм
уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә
2нче Кушымта

**ИНИЦИАТИВ ТӨРКЕМ ӘГЪЗАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Фамилиясе, исеме, атасынын исеме һәм туган елы (18 яшьтэ- туган елы һәм ае) | Яшәу урыны адресы | Паспорт мәгълүмәтләре (шәхесне раслый торган документ сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгәнлеге) | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданнарнын инициатив
төркеменең вәкаләтле вәкиле ___________________ _________
(имза) (Ф. И. О.)

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 3нче Кушымта

## АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕ

« ________________________________________________________________________

________________________________________________________ » мәсьәләсе буенча:

Без, түбәндә имза куючылар,

________________________________________________________ ” мәсьәләсе буенча муниципаль берәмлек халкының инициативасы буенча ачык тыңлаулар үткәрүне хуплыйбыз,

| № п/п | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туган елы (18 яшьтэн- туган елы һәм ае) | Яшәү урыны, адресы | Гражданның паспортының яки паспортны алыштыручы документының сериясе һәм номеры | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Язылу кәгазен
таныклыйм ________________________________________________________

Фамилиясе, исеме, атасының исеме, гражданның паспортының яки паспортны алыштыручы документының сериясе һәм номеры (аны аңа биргән органның исемен яки кодын курсәтеп), имза жыючы затның яшәу урыны, имзасы һәм аны кертү датасы).

Гражданнарның инициатив
төркеменең вәкаләтле вәкиле ____________________ ________________

(имза) (Ф. И. О.)

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 4нче Кушымта

**АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕН ТИКШЕРУ БЕРКЕТМӘСЕ**

«________________

мәсьәләсе буенча:

“Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы _______авыл жирлеге " муниципаль берәмлеге Советына ачык тыңлаулар уздыруны хуплаган гражданнарның тәкьдим ителгән имзалар саны

Сайлаучыларның имзалары тикшерелгән ____________ , шуларның ___ гамәлдә булмаган дип табылды:

________________ түбәндәге сәбәпләр буенча:

Гамәлдә тугел дип табылган имзалар саны -

Советка хакыйкый тәкьдим ителгән гамәлдә дип табылган имзаларның гомуми саны тәшкил итә: ____________________ .

Эш төркеме житәкчесе ____________________ ____________________

(имза) (Ф.И.О.)

Эш төркеме әгъзалары ____________________ ______________

(имза) (Ф.И.О.)

(имза) (Ф.И.О.)

(дата, вакыт)

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле

(имза) (Ф.И.О.)

Гражданнарның инициатив төркеме сәркатибе

(имза) (Ф.И.О.)

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 5нче Кушымта

**АЧЫК ТЫҢЛАУЛАР БЕРКЕТМӘСЕ**

« » 20 ел. №

Инициатива буенча ачык тыңлаулар:
_______________________________________________ билгеләнгән
дан №

(муниципаль хокукый акт)

(муниципаль хокукый акт исеме)
бастырылган
(халыкка җиткерелгән): ____________________________________ уткәрелгән
_______________________________________________ адрес буенча:

(үткәрү вакыты)

Оештыру комитеты: ____________________________________

Катнаштылар: ____________________________________

Рәислек итүче: ____________________________________

Сәркатип: ____________________________________

Экспертлар: ____________________________________

Ачык тыңлауларда катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны)

Ачык тыңлауларда булган катнашучылар:

(Ф.И.О.)

Тыңлаучылар :
1. ____________________________________
(Ф.И.О.)
2. ____________________________________
(Ф.И.О.)
3. ____________________________________
(Ф.И.О.)

Телдән һәм язма рәвештә кертелгән рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр саны, ________________________, шул исәптән:

| № п/п | Рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр | Гариза бирүче |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Ачык тыңлауларда рәислек итүче: ________________ ______________
(имза) (Ф. И. О.)

Ачык тыңлауларның сәркатибе: ________________ ____________
(имза) (Ф. И. О.)

«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 6нчы Кушымта

# ХАЛЫК АЛДЫНДА ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ НӘТИЖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

«__ »_________ 20 __ел.

Инициатива буенча ачык тыңлаулар:
билгеләнгән

(муниципаль хокукый акт)

№

( муниципаль хокукый акт исеме)

бастырылган
(халыкка җиткерелгән:___________________________________ үткәрелгән
_____________________________________________________________ адрес буенча:
(үткәрү датасы)

**Ачык тыңлауларга чыгарылган сорау (сораулар)** _________________________
**Ачык тыңлаулар үткәрүнең инициаторы**__________________________________
**Ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны**
**Ачык тыңлаулар уткәруче оештыру комитеты** ____

**Ачык тыңлауларда катнашучылар турында, шул исәптән катнашырга хокук алганнар турында мәгълумат**

Ачык тыңлауларда катнашучыларнын тавыш бирү нәтиҗәләре:

яклап __________________(кеше)
каршы____________________ (кеше)
икеләнгән_________________ (кеше)

**Ачык тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияткә ия сорау (сораулар) буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнен, бердәм исемлеге:**

| Фикер алышуга чыгарылган сораулар | | Экспертларнын һәм катнашучыларнын тәкъдимнәре һәм кинәшләре | | Тәкъдимнәр, рекомендацияләр) кертелә хуплана) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | Сорау формулиров-касы яки проект атамасы | № п/п | Тәкъдим тексты | Катнашучы экспертынын Ф.И.О. | |
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты:

Оештыру комитеты рәисе

Оештыру комитеты сәркатибе